РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 20 » 04 2021 ел № 315

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 гыйнварындагы 113 санлы карары белән расланган «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2009 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында»гы 381-ФЭ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2016 елның 13 августындагы «Муниципаль милектә булган җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы 553 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2020 елның 28 апрелендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 18 санлы карары белән кабул ителгән Уставы, 2006 елның 12 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 31 гыйнварындагы 113 санлы карары белән расланган «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.6. бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында Россия ФСХНнән мәгълүматлар.»;

1.2. 2 бүлекнең 2.8. бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 5 абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»;

1.3. 2 бүлекнең 2.9. бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 10 абзац өстәргә:

«8) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу турында Россия Федераль салым хезмәтеннән мәгълүмат керү.»;

1.4. 3.4 бүлегенең 3.4.1 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 6 абзац өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С.П.Самонина